Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының
Өркеш авыл җирлеге башкарма комитеты

# Карар

2021 елның «23» сентябре № 16

Муниципаль мөлкәтне, җир кишәрлекләрен яисә аларны арендалау хокукларын сату, муниципаль мөлкәтне түләүсез файдалануга тапшыру, ышанычлы идарә итү буенча бәйге (аукцион) комиссиясе турында НИГЕЗЛӘМӘне раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.11, 39.12.12 статьялары, Россия Федерациясе Граждан кодексының 447, 448, 449 статьялары, «Аукционда дәүләт мөлкәтен сатуны оештыру турындагы Нигезләмәне һәм махсуслаштырылган аукционда ачык акционер җәмгыятьләрнең дәүләт яисә муниципаль милектә булган акцияләрен сатуны оештыру турындагы Нигезләмәне раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2002 елның 12 августындагы 585 номерлы Карары, «Аренда шартнамәләре, түләүсез файдалану шартнамәләре, мөлкәт белән ышанычлы идарә итү шартнамәләре, дәүләт яисә муниципаль мөлкәткә карата хокукларның күчүен күздә тотучы башка шартнамәләр төзү хокукына бәйгеләр яисә аукционнар уздыру тәртибе турында һәм күрсәтелгән шартнамәләр төзү конкурс рәвешендә торглар үткәрү юлы белән гамәлгә ашырылырга мөмкин булган мөлкәт төрләре исемлеге турында» Федераль антимонополия хезмәтенең 2010 елның 10 февралендәге 67 номерлы приказы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Өркеш авыл җирлеге Уставы нигезендә карар бирәм:

1. Муниципаль мөлкәтне, җир кишәрлекләрен яисә аларны арендалау хокукларын сату, муниципаль мөлкәтне түләүсез файдалануга тапшыру, ышанычлы идарә итү буенча бәйге (аукцион) комиссиясе турында НИГЕЗЛӘМӘне расларга (1 нче кушымта).

2. Муниципаль мөлкәтне, җир кишәрлекләрен яисә аларны арендалау хокукларын сату, муниципаль мөлкәтне түләүсез файдалануга тапшыру, ышанычлы идарә итү буенча бәйге (аукцион) комиссиясе составын расларга». (2 нче кушымта)

3. 2017 елның 7 августыннан 2 номерлы Өркеш авыл башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегенә урнаштырырга.

Өркеш авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе: А.Ш.Әгъләмова

2021 елның 23 сентябре 16 номерлы Өркеш авыл җирлеге башкарма комитеты карарына 1 нче кушымта

**Муниципаль мөлкәтне, җир кишәрлекләрен яисә аларны арендалау хокукларын сату, муниципаль мөлкәтне түләүсез файдалануга тапшыру, ышанычлы идарә итү буенча бәйге (аукцион) комиссиясе турында**

**НИГЕЗЛӘМӘ**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Муниципаль мөлкәтне, җир кишәрлекләрен яисә аларны арендалау хокукларын сату, муниципаль мөлкәтне түләүсез файдалануга тапшыру, ышанычлы идарә итү буенча аукционнарны әзерләү һәм уздыру комиссиясе (алга таба – комиссия) күчемле һәм күчемсез муниципаль милекне, җир кишәрлекләрен, мөлкәтне, җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәләрен төзүгә хокукны сату буенча барлык мәсьәләләрне карауны һәм хәл итүне тәэмин итүче даими рәвештә эшләүче киңәшмә орган булып тора.

1.2. Комиссия үз эшчәнлегендә «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль законга, «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.11, 39.12.12 статьяларына, Россия Федерациясе Граждан кодексының 447, 448, 449 статьяларына, «Аукционда дәүләт мөлкәтен сатуны оештыру турындагы Нигезләмәне һәм махсуслаштырылган аукционда ачык акционер җәмгыятьләрнең дәүләт яисә муниципаль милектә булган акцияләрен сатуны оештыру турындагы Нигезләмәне раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2002 елның 12 августындагы 585 номерлы Карарына, «Аренда шартнамәләре, түләүсез файдалану шартнамәләре, мөлкәт белән ышанычлы идарә итү шартнамәләре, дәүләт яисә муниципаль мөлкәткә карата хокукларның күчүен күздә тотучы башка шартнамәләр төзү хокукына бәйгеләр яисә аукционнар уздыру тәртибе турында һәм күрсәтелгән шартнамәләр төзү конкурс рәвешендә торглар үткәрү юлы белән гамәлгә ашырылырга мөмкин булган мөлкәт төрләре исемлеге турында» Федераль антимонополия хезмәтенең 2010 елның 10 февралендәге 67 номерлы Приказына, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Починок-Кучук авыл җирлеге Уставына һәм әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.3. Нигезләмә муниципаль мөлкәтне, җир кишәрлекләрен яисә аларны арендалау хокукларын сату, муниципаль мөлкәтне түләүсез файдалануга тапшыру, ышанычлы идарә итү буенча торглар (аукционнар һәм конкурслар) уздырганда комиссиянең вәкаләтләрен һәм эш тәртибен билгели.

2. Комиссиянең вәкаләтләре

2.1.Комиссия түбәндәгеләрне торглар үткәрү турында хәбәрләр белән билгеләнә торган срокларда:

2.1.1. Дәгъвачылардан кабул ителгән гаризаларны аларга теркәлә торган документлар белән карый, дәгъвачылар тарафыннан тапшырылган документларны рәсмиләштерүнең дөреслеген тикшерә һәм аларны Россия Федерациясе законнары таләпләренә һәм торглар үткәрү турында хәбәрдә бастырылган исемлеккә туры килүен билгели, дәгъвачылардан тиешле счеттан өземтә (өземтәләр) нигезендә бурычлар керү фактын билгели;

2.1.2. Дәгъвачыларны аукционда (бәйгедә) катнашучылар итеп тану турында, яисә гамәлдәге законнарда каралган нигезләрдә аукционда (бәйгедә) катнашуга кертүдән баш тарту турында карар кабул итә;

2.1.3. Аукцион (конкурс) җиңүчесен билгели.

2.2. Дәгъвачылар заявкаларын карау нәтиҗәләре турында комиссия карарлары аукционда катнашуга (дәгъвачыларны торгларда катнашучылар итеп тану турында) заявкалар кабул итү беркетмәләре белән рәсмиләштерелә .

Комиссиянең аукцион (бәйге) йомгаклары турындагы карарлары, аның җиңүчесен билгеләп, аукцион беркетмәләре белән, аукцион нәтиҗәләре турында (торглар нәтиҗәләре турындагы беркетмәләр белән) рәсмиләштерелә.

Беркетмәләргә комиссия утырышында катнашучы комиссия әгъзалары имза сала

2.3. Комиссия бирелгән документларның комиссия эше вакытында сакланышын тәэмин итү, шулай ук заявкалар биргән затлар турында белешмәләрнең конфиденциальлеге һәм тапшырылган документларның эчтәлеге өчен җаваплы.

## 3. Комиссиянең эш тәртибе

3.1. Комиссия муниципаль мөлкәтне, җир кишәрлекләрен яисә аларны арендалау хокукларын сату, муниципаль мөлкәтне түләүсез файдалануга тапшыру, ышанычлы идарә итү буенча торглар (аукционнар һәм конкурслар) уздыру өчен төзелә торган коллегиаль орган булып тора.

3.2. Комиссия утырышлары торглар үткәрү турында хәбәрнамәдә билгеләнгән срокларда уздырыла.

3.3. Комиссия утырышында аның әгъзаларының гомуми санының кимендә илле проценты катнашса, комиссия үзенә йөкләнгән вазыйфаларны башкарырга хокуклы.

3.4. Комиссия утырышлары аерым бинада/бүлмәдә уздырыла.

3.5. Комиссия әгъзалары утырышларда шәхсән үзләре катнаша һәм комиссия утырышлары беркетмәләренә имза сала.

3.6. Комиссия утырышлары аның рәисе тарафыннан ачыла һәм ябыла.

3.7. Карарлар утырышта катнашучы комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Комиссиянең һәр әгъзасы бер тавышка ия. Тавышлар тигез булганда, рәис тавышы хәлиткеч булып тора.

3.8. Комиссия бирелгән документларның комиссия эше вакытында сакланышын тәэмин итә, шулай ук заявкалар биргән затлар турында белешмәләрнең һәм тапшырылган документларның эчтәлегенең конфиденциальлеген тәэмин итә.

3.9. Комиссия утырышлары йомгаклары тиешле беркетмәләр белән рәсмиләштерелә. Беркетмәләрнең төп нөсхәләре торгларны оештыручыларда саклана.

## 4. Комиссиянең функцияләре

Үз бурычларын гамәлгә ашыру максатларында Комиссия түбәндәге функцияләрне башкара:

4.1. Торг дәгъвачыларын торгларда катнашучылар итеп тану турында, яисә аларны торгларда катнашуга кертүдән баш тарту турында карар кабул итә, шул ук вакытта дәгъвачыларны гамәлдәге законнарда каралмаган нигезләрдә торгларда катнашуга кертүдән баш тарту рөхсәт ителми;

4.2. Дәгъвачыларга кабул ителгән карар турында хәбәр итә;

4.3. заявкалары булган конвертларны ачуны гамәлгә ашыра, бирелгән заявкаларны конкурс (конкурс рәвешендә торглар уздырганда) шартларында билгеләнгән төп критерийлар нигезендә бәяли;

4.4. Торгларны оештыручы һәм (яисә) аукциончы тарафыннан (аукцион формасында торглар уздырганда) торглар уздыруга кагылышлы мәсьәләләрне хәл итә;

4.5. Торгларда җиңүчеләрне билгели, йә бердәнбер катнашучы яки бердәнбер мөрәҗәгать итүче белән килешү төзи, йә торгларны узмаган дип таный.

4.6. Торглар нәтиҗәләрен игълан итә;

4.7. Комиссия утырышлары беркетмәләрен төзи;

4.8. Торгларда катнашучыларның шикаятьләрен карый.

## 5. Комиссия составы

5.1. Комиссия составы Починок-Кучук авыл башкарма комитеты карары белән раслана. Комиссия кимендә биш әгъзадан тора, аңа Комиссия рәисе, Комиссия рәисе урынбасары, Комиссия секретаре, шулай ук Комиссия әгъзалары керә.

5.2. Торглар нәтиҗәләре белән кызыксынган затлар Комиссия әгъзалары була алмый.

## 6. Комиссиянең хокуклары

Үзенә йөкләнгән вазыйфаларны үтәү өчен комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

6.1. Торгларда катнашуга дәгъва кылучыларның заявкаларын һәм документларын тикшерергә;

6.2. Тиешле счеттан (счетлардан) өземтә (өземтәләр) нигезендә торгларда катнашкан өчен дәгъвачылардан бурыч керү фактын билгеләргә;

6.3. Гамәлдәге кануннарда каралган очракларда торгларны узмаган дип тану турында карар кабул итәргә.

## Комиссия әгъзаларының бурычлары

7.1. Комиссия әгъзалары бурычлы:

7.1.1. үз эшчәнлекләрендә әлеге Нигезләмә таләпләренә таянып эш итәргә;

7.1.2. Комиссия утырышларында шәхсән катнашырга;

7.1.3. Үз бурычларын үтәгәндә мәгълүм булган мәгълүматның конфиденциальлеген сакларга.

7.2. Комиссия рәисе, рәис урынбасары һәм Комиссия әгъзалары дәгъвачыларны торгларда катнашучылар дип тану турындагы беркетмәгә кул куялар һәм кабул ителә торган карарларның гамәлдәге законнарга туры килүе өчен җаваплылык тоталар.

7.3. Комиссия рәисе:

7.3.1. Комиссиягә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен шәхси җаваплылык тота, шулай ук:

7.3.2. Комиссия эшчәнлегенә җитәкчелек итә һәм торглар уздырганда гамәлдәге законнар, шулай ук әлеге Нигезләмә таләпләрен үтәүне тәэмин итә;

7.3.3. Комиссия утырышларында рәислек итә һәм аның эшен оештыра;

7.3.4. Утырышны хокуклы дип игълан итә яисә, Комиссия әгъзаларының кирәкле саны булмаганга күрә, аны күчерү турында карар чыгара;

7.3.5. тикшерелә торган мәсьәләләрне карау тәртибен игълан итә;

7.3.6. Комиссиянең утырышлар беркетмәләренә имза сала;

7.3.7. Торглар җиңүчесен игълан итә;

7.3.7. гамәлдәге законнар нигезендә Комиссия эше белән бәйле башка гамәлләрне тормышка ашыра.

7.4. Комиссия рәисе урынбасары рәис үзе булмаганда рәис вәкаләтләрен башкара.

7.5. Комиссия секретаре:

7.5.1. Комиссия әгъзаларына Комиссия утырышы көненә кадәр өч көн кала, аны уздыру көне, урыны һәм вакыты турында хәбәр итә;

7.5.2. Комиссия утырышларының беркетмәләрен алып бара һәм аларны тиешенчә рәсмиләштерүне һәм урнаштыруны тәэмин итә;

7.5.3. Торг дәгъвачыларына Комиссия кабул иткән карар турында хәбәр итә.

## 8. Комиссия карарларына шикаять белдерү

Комиссия карарларына гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

## 9. Комиссия әгъзаларының җаваплылыгы

Комиссия әгъзалары үз бурычларын үтәмәгән (тиешенчә үтәмәгән) өчен дисциплинар, гражданлык-хокукый, административ, җинаять җаваплылыгына тартылалар.

2021 елның 23 сентябре
16 номерлы Өркеш авыл
җирлеге башкарма комитеты
карарына 2 нче кушымта

муниципаль мөлкәтне, җир кишәрлекләрен яисә аларны арендалау хокукларын сату, муниципаль мөлкәтне түләүсез файдалануга тапшыру, ышанычлы идарә итү буенча комиссия СОСТАВЫ

| | |
|---|---|
| Әгъләмова Альбина Шамил кызы | Өркеш авыл җирлеге башлыгы, комиссия рәисе; |
| Йосыпова Зөһрә Фәнил кызы | Өркеш авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре, комиссия секретаре; |
| Комиссия рәисе урынбасары: | |
| Исламов Радик Ибраһим улы | Өркеш авыл җирлеге Советы депутаты (килешү буенча); |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Ярмөхәметов Илгиз Мансур улы | Өркеш авыл җирлеге Советы депутаты (килешү буенча); |
| Ярмөхәметов Азат Вәлиәхмәт улы | Өркеш авыл җирлеге Советы депутаты (килешү буенча). |